РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**15.12.2025** Кукмара ш. **№ 683**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 21 декабрендәге 753 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчалары) гаризалар кабул итү, исәпкә кую һәм балаларны кабул итү» муниципаль хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 21 декабрендәге 753 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчалары) гаризалар кабул итү, исәпкә кую һәм балаларны кабул итү» муниципаль хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына, (Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 21 октябрендәге 556 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.7 пунктның дүртенче һәм унсигезенче абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

2) 2.8.2 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8.2. Россия Федерациясе гражданы паспорты яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә яисә муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнарда, күпфункцияле үзәкләрдә, «Физик затларны биометрик персональ белешмәләрдән файдаланып идентификацияләүне һәм (яисә) аутентификацияләүне гамәлгә ашыру турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 572-ФЗ номерлы Федераль законның 9, 10 һәм 14 статьяларында каралган мәгълүмат технологияләрен кулланып, идентификацияләү һәм аутентификацияләү юлы белән шәхесне таныклый торган башка документ.»;

3) түбәндәге эчтәлекле 2.11.4 пунктын өстәргә:

«2.11.4. Электрон образлары элек 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны кәгазь чыганакта бирү, мондый документларга тамга салу йә аларны алып ату дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торса, һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.»;

4) 2.14 пунктының сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль белем бирү оешмасында буш урыннарның булмавы, шулай ук «Россия Федерациясендә белем бирү турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 78 статьясындагы 2.1 өлешендә билгеләнгән шартлар үтәлмәгәндә, «Россия Федерациясендә белем бирү турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә һәм 88 статьясында каралган очраклардан тыш, төп нәтиҗә өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булырга мөмкин, Муниципаль белем бирү оешмасында урыннар булмаган очракта, баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) аны башка гомуми белем бирү оешмасына урнаштыру мәсьәләсен хәл итү өчен турыдан-туры мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органына мөрәҗәгать итәләр.»;

5) 2.15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.15. Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.»;

6) 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәткәндә, гариза бирүчегә өстәмә рәвештә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат алу;

хезмәт күрсәтү турында гарызнамә бирү өчен органга, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә (алга таба – күпфункцияле үзәк) кабул итүгә язылу (алга таба –сорату);

соратуны формалаштыру;

хезмәт күрсәтү өчен кирәкле соратуларны һәм башка документларны орган тарафыннан кабул итү һәм теркәү;

хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу;

соратуны үтәүнең барышы турында белешмәләр алу;

хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашыру;

гариза бирүчегә гариза бирүче билгеләренә туры килә торган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында каралган вариантын билгеләү максатларында анкета бирү (гариза бирүчегә сораулар исемлеген һәм күрсәтелгән сорауларга җаваплар вариантларының тулы исемлеген күрсәтү);

гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүнең муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында каралган вариантын күрсәтү;

Вәкаләтле органның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата яисә Вәкаләтле органның муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затларының яисә муниципаль хезмәткәрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү.»;

7) 3.3 пунктының дүртенче һәм бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гаризаны формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан орган билгеләгән таләпләр нигезендә, гариза бирүче тарафыннан соратуның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал тарафыннан гаризаның электрон формасындагы дөрес тутырылмаган кыр ачыкланганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны турыдан-туры гаризаның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

ЕПГУ һәм/яисә РПГУ аша гариза формалаштырганда гариза бирүчегә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм башка документларны күчермәләү (копирование) һәм саклау мөмкинлеге;

б) берничә мөрәҗәгать итүче тарафыннан уртак гариза җибәрүне күз алдында тоткан хезмәтләр сорап мөрәҗәгать иткәндә, берничә гариза бирүченең бер электрон гариза формасын тутыру мөмкинлеге;

в) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

г) кулланучының теләге буенча электрон сорату формасына элек кертелгән күрсәткечләрне теләсә кайсы мизгелдә саклап калу, шул исәптән, керткәндә хаталар барлыкка килгәндә һәм гаризаның электрон формасына күрсәткечләрне кабат кертү өчен кире кайтарылганда;

д) гариза бирүче белешмәләр кертә башлаганчы, «Электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган белешмәләрдән, Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында булмаган белешмәләргә кагылышлы өлешендә Бердәм порталда, хезмәт күрсәтү порталларында яисә рәсми сайтларда бастырылган белешмәләрдән файдаланып, гаризаның электрон рәвешендәге кырларын тутыру;

е) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гаризаның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына әйләнеп кайту мөмкинлеге;

ж) гариза бирүченең Бердәм порталда, хезмәтләр порталында яки рәсми сайтта элек бирелгән соратуларга кимендә бер ел эчендә, шулай ук өлешчә формалаштырылган соратуларга – кимендә 3 ай эчендә керә алу мөмкинлеге булу.

ЕПГУ һәм/яисә РПГУда формалаштырылган гариза Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем файдалана алырлык төбәк мәгълүмат системасына җибәрелә.»;

8) 3.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацларны өстәргә:

«Балигъ булмаган затка карата муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен балигъ булмаган затның гариза бирүче булып торучы законлы вәкиле алганда, балигъ булмаган затка карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен алу хокукын гамәлгә ашыру балигъ булмаган затның гариза бирүче булмаган законлы вәкиле тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу очракта балигъ булмаган затның законлы вәкиле булган гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаган затның балигъ булмаган затка карата тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алырга вәкаләтле башка законлы вәкиленең фамилиясен, исемен, этисенең исемен (булган очракта), шәхесен таныклый торган документ турында белешмәләрне күрсәтә.

Балигъ булмаган затка карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләре, әгәр гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаган затка карата дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сорала торган нәтиҗәләрен шәхсән үзе алырга теләк белдергән булса, балигъ булмаган затның башка законлы вәкиленә бирелә алмый.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**